СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**26 январь 2016 ел** **№ 13**

## Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районыныңУтар-Атыавыл җирлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2016 елның 22 гыйнварындагыУтар-Атыавыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендәУтар-Атыавыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартынаУтар-Аты авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2016 елдаУтар-Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) 1әм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | - Утар-Аты авылының Мәктәп урамында яктырткычлар алыштыру һәм урнаштыру; | 6000 |
| 2 | Күмү урыннарын карап тоту | - зират коймаларын урнаштыру;:<br>Югары Аты авылы ,<br>Иске Җөлбә авылы | <br>82500<br>7250 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту | - юлларга вак таш салу. : Утар Аты авылы<br>Субаш Аты авылы<br>Орнашбаш авылы<br>Иске Җөлбә авылы<br>Кушлавыч авылы<br>- җәяүлеләр күперләрен ремонтлау;:<br>Орнашбаш авылы<br>Утар-Аты авылы | <br>104500<br>68500<br>100000<br>7250<br>16000<br><br><br>6000<br>6000 |
| | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - Кушлавыч авылында Тукай урамында кое төзелеше. | 12500 |
| | | Барлыгы: | 416500 |

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Арча районы,Утар-Аты авылы, Кооператив ур., 22 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Орнашбаш авылы, Яшләр ур., 6 йорт, Татарстан Республикасы, Арча районы, Югары Аты авылы, Кооператив ур., 22 йорт, Татарстан Республикасы, Арча районы, Кушлавыч авылы, Тукай ур.; 1 йорт.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Утар-Аты авыл
җирлеге башлыгы А.Г.Хәкимҗанов

СОВЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ